**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГАЙТАНКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ГӘЙТӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423014, РТ, Нурлатский район, с. Гайтанкино, ул. Садовая, дом 17
Тел. 8 (84345) 3-98-01

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06 апрель 2026 ел № 4

«2026-2030 елларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гәйтән авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасын раслау турында

Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү һәм эшкуарлык эшчәнлеген булдыру максатларында «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Нурлат муниципаль районының Гәйтән авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеге алып бару өчен уңайлы икътисадый мохит булдыру максатларында, Нурлат муниципаль районының Гәйтән авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «2026-2030 елларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гәйтән авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасын әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм җирлек территориясендә мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Гәйтән авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Н.В. Авдеева